Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе «Дусай балалар бакчасы»

| Наименование проекта | **«Чишмәләр иленә –туган телемдә!»**<br>**«На родном языке в страну родников!»** |
|---|---|
| Цель и задачи проекта | Воспитание нравственно-патриотических чувств у детей через обучение родному языку, изучение традиций и культуры народов, проживающих на территории Республики Татарстан.<br>**Задачи проекта:**<br>1. Формировать у подрастающего поколения чувство национальной гордости за родной язык и культуру всех народов;<br>2. Формировать духовно-нравственные отношения и патриотические чувства, сопричастности к своей Родине, Республике, родному дому, семье.<br>3. Показать самобытность народов, проявляющуюся в творчестве народных умельцев, в устном народном творчестве, в их быте и традициях;<br>4. Развивать у детей творческую и познавательную активность;<br>5. Организовать совместные мероприятия разных форм с родительской общественностью, с социальными партнерами, а так же жителями деревни Дусай;<br>6. Актуализировать имеющийся опыт духовно-нравственного и культурного воспитания в системе дошкольного образования: создать условия для активизации, содержательного обогащения и систематизации имеющегося материала по данной теме. |
| Сроки реализации | 01.01.2024-31.12.2024 |
| Обоснование значимости проекта | Задача обеспечения качественного воспитания и дошкольного образования и равного доступа к ним для всех детей независимо от социального, экономического и культурного уровня их семей — одна из ключевых для современного образования. В связи с этим становится все более актуальным понимание качества работы детского сада как её способности повышать жизненные шансы каждого воспитанника независимо от индивидуальных стартовых возможностей и семейных условий, в том числе по сохранению родного языка и культуры.<br>Язык - это характер народа, его память история и духовное могущество. В нем отражаются обычаи, традиции, быт народа, ум, опыт и его красота.<br>Татарстан – многонациональная республика, с многовековой историей, уходящий своими корнями в вековое прошлое. В ней проживает большое количество разных народов, которые отличаются друг от друга своими обычаями и традициями. Все они говорят на разных языках и имеют свою самобытную культуру. Но чтобы сохранить мир и взаимопонимание между этими народами - важно знать как можно больше друг о друге, тогда и общатся будет легко, и сохранить дружбу народов. Традиции народа живут и передаются из поколения в поколение. Язык жив только тогда, когда на нем говорят, общаются, создают художественные произведения.<br>Приобщение детей дошкольного возраста к народной культуре является средством формирования у них патриотических чувств и развития нравственности и духовности. И дети и взрослые должны знать, как важно всем народам нашего Отечества и всей Планеты жить в мире и согласии между собой.<br>В целях сохранения родных языков и народных традиций предпринимается ряд мер как со стороны общественности, так и соответствующих структур, но эту работу необходимо значительно |

| | |
|---|---|
| | усилить. Учитывая, что дальнейшее развитие народа органично связано с возрождением его культуры, ведь культура – это воплощение народа, его душа, глубина. И если старшее поколение в определенной степени знает язык, культуру, традиции народа, то подрастающее поколение необходимо к ним активно приобщать.<br>Актуальность проекта «Чишмәләр иленә – туган телемдә!» - «На родном языке в страну родников!» обусловлена потребностью сохранения и развития родного языка, культуры, традиций народов, проживающих на территории Республики Татарстан. В рамках проекта проводится ряд мероприятий с привлечением общественности: праздники, встречи, театрализованные постановки, акции, экскурсии, создана предметно-развивающая среда, которые охватят большой круг целевой аудитории. Итогом проекта станет фольклорный фестиваль «Наследие народов Татарстана» на сцене родной деревни Дусай в клубе.<br>Проект «Чишмәләр иленә – туган телемдә!» - «На родном языке в страну родников!» является логическим продолжением воспитательно – образовательной деятельности нашего детского сада и содействует решению проблемы сохранения родных языков, возрождения и развития национальных и культурных традиций, осуществлению мер по поддержке творческой деятельности воспитанников, педагогических работников и родителей.<br>Дошкольный возраст – самый благоприятный период для формирования у детей чувства патриотизма: любви и привязанности к Родине, преданности ей, ответственности за неё, желания трудиться на благо, беречь и умножать её богатства. Приобщение к традициям народа особенно значимо в дошкольные годы. Патриотическое воспитание дошкольников включает в себя передачу знаний и организацию доступной деятельности.<br>Невозможно воспитать в подрастающем поколении чувства собственного достоинства, уверенности в себе, а значит полноценную личность, без уважения к истории, традициям и культуре своего Отечества, к его государственной символике. Невозможно стать патриотом, не чувствуя личной связи с Родиной, не зная как любили и берегли её наши предки.<br>В детском саду в результате целенаправленной, систематической воспитательной работы у детей могут быть сформированы элементы гражданственности и патриотизма. В настоящее время возникает необходимость в том, чтобы ребенок почувствовал уникальность своего народа, знал историю своей семьи, страны, мира, возлюбил свою Родину, пришел к пониманию и осознанию собственной неповторимости, к значимости каждого человека, живущего на земле. |
| Целевые группы проекта | Все воспитанники, педагоги и родители МБДОУ «Дусаевский детский сад» Мамадышского муниципального района Республики Татарстан, жители деревни Дусай и село Тулбай. |
| Ожидаемые количественные и качественные результаты проекта | Настоящий проект является инструментом для деятельности образовательной организации по созданию этнокультурной воспитательной и образовательной среды, способствующей сохранению и развитию родных языков, национальных и культурных традиций народов Татарстана и направлен на достижение следующих результатов:<br>- повышение уровня знаний, умений и навыков воспитанников в использовании родного языка в общении между сверстниками, приобщение их к этнокультурным традициям народов, проживающих на территории Республики Татарстан; |

| | |
|---|---|
| | - наличие у детей представлений о культурных традициях, образе жизни, народных промыслов народов, умения различать изделия разных народных промыслов;<br>- формирование у детей уважения к историческому наследию; интереса к истории и культуре народов РТ;<br>- умение детей различать жанры и виды произведений народного искусства, а также фольклора;<br>- наличие творческих проявлений в декоративно-прикладной, изобразительной, музыкальной, художественно-речевой и театральной деятельности;<br>- повышение результатов участия воспитанников в конкурсах, акциях, посвященных родным языкам;<br>- формирование компетентности родителей в вопросах обучения детей двум государственным языкам Республики, сохранению родного языка, воспитания любви и уважения национальным традициям народов;<br>- получение доступа к культурно-образовательным ресурсам путем создания информационно-этно-культурно-образовательно-развивающей среды;<br>- повышение квалификации и формирование профессиональных компетенций педагогических работников детского сада в области дошкольного образования детей и духовно-нравственного воспитания, направленного на сохранение и развитие родных языков, традиций и культуры народов Татарстана;<br>- привлечение культурных и общественных организаций в проведении совместных мероприятий;<br>- создание предметно-развивающей среды по обучению детей двум государственным языкам, по этнокультурному образованию в целом;<br>- создание презентации проекта;<br>- создание методического сборника материалов по итогам проекта. |
| Бюджет проекта | 500 тысяч рублей |
| Информация о руководителе проекта | Зиганшина Алсу Мансуровна с 10.10.1989 года - воспитатель в МБДОУ «Дусаевский детский сад» Мамадышского муниципального района Республики Татарстан, с 01.09.2009 года - заведующий.<br>Имеет высшее педагогическое образование. Стаж работы - 42 года.<br>Награждена нагрудным Знаком «За заслуги в образовании» (2020г.), Почетной Грамотой Министерства просвещения РФ в 2024г. |
| Команда проекта | Коллектив МБДОУ «Дусаевский детский сад» Мамадышского муниципального района Республики Татарстан.<br>Педагогический коллектив ДОУ в своей работе с детьми по сохраннию родных языков и традиций народов РТ использует различные формы и методы, инновационные технологии, активно сотрудничает с родительским сообществом и социальными партнерами. |
| Партнеры проекта | Районная общественная организация женщин «Ак калфак»; Общественная организация Всемирного Конгресса татар в Мамадышском МР РТ;<br>Тулбаевский музей–библиотека имени Шайхи Маннура;<br>Школьный военно-патриотический музей «Молодая гвардия» МБОУ «Таканышская СОШ». |

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем учреждениесе «Дусай балалар бакчасы»

«Чишмәләр иленә –туган телемдә!»
«На родном языке в страну родников!»

*Максаты:*
*Гаилә белән, халкымның күркәм гатәтләре аша - татар теленә өйрәтү, ныгыту һәм үстерү өчен белем бирү мөхите булдырып, балаларның татар телендә иркен сөйләшә алуларын җитди үстерү һәм буыннар арасында ныклы бәйләнеш булдыру.*
Бурычлар:
1. Туган телебезне ярату, аңа карата ихтирам тәрбияләү.
2. Дөрес һәм эзлекле сөйләм телен үстерү.
3. Милли гореф-гадәтләр, йолалар, бәйрәмнәр, татар халкының милли мирасы, әкиятләр, уеннар аша балаларга һәм ата-аналарга туган телне өйрәнүгә этәргеч бирү.
4. Балада туган йортына, гаиләсенә, кече ватанына- авылына, туган җиренә ярату хисе тәрбияләү, гаилә турында күзаллау формалаштыру.
5.Проект эшенә гаилә, социаль партнерларны җәлеп итү.
6. Ата-аналар арасында, гаиләдә татар телен популярлаштыру.

Безнең проектның исеме «Чишмәләр иленә –туган телемдә!» *дип атала.*
Чишмәләр бит алар чыннан да үзләре бер донья.Һәр авылның үз чишмәләре бар. Борынгыдан ук кешеләр бу су чыганакларына матур-матур исемнәр биргәннәр. Һәр-берсенең үз тарихы, үз моңы, үз агымы, үз юлы . Чишмәнең исеме артында кайвакыт борынгы, халык хәтерендә өзек-өзек кенә сакланган вакыйгалар, язмышлар тора. Күп гасырлар чишмә кешелек өчен яшәү, илһам чыганагы булган. Күпме шигырьләр , җырлар иҗат ителгән.Чишмә– су чыганагы гына түгел, рухыбыз көзгесе дә. *Чишмә– безне үткәнебез һәм киләчәк белән бәйләүче тере җеп тә.*
Безнең балалар бакчасыннан чыгу белән ямь яшел чирәмлек, бераз гына барасын һәм Шыя елгасы, бу елга ярында "Җәмил"һәм "Ибрай" чишмәләре. Без балалар белән һәрдаим чишмәгә барабыз, иркендә уйнап кайтабыз. Инде алар Һәрвакыт, чишмәгә барабызмы? дигән сорау бирә башладылар. Чишмәләр безне үзләренә тартып торалар. Алар чишмә янына килеп җитүгә "Сәлам чишмә, Сәлам!" дип исәнләшә башладылар.Чишмә дә аларга "челтер –челтер" килеп, сәламләгән кебек. Ә балалар үзара голдер- голдер килә. Шул вакытларның берсендә миңа фикер килде,чишмәләрне проект эшенә алырга була икән бит. Һәм инде без көздән планнарыбызны тормышка ашыра башладык.Чиратлашып чишмәләргә йөрдек.*Күп вакыт балалар белән чишмә буйларында булу, аларны табигатькә якынайта. Үсеп килүче кешедә күзәтүчәнлек сәләте ояту, табигать дөньясына колак салу, чишмәләребезнең матурлыгына, хуш исе белән хозурланугадәтен үстермичә мөмкин түгел- чөнки бала яңа сүзләр белән таныша.* Чишмәләр иле *мавыктыргыч формада, тел тирәлегенә чумып балаларга татар телебезне өйрәнергә мөмкинлек бирә, анда сабыйлар табигый рәвештә уен һәм иҗат эшчәнлеге аша татар теле нигезләрен ала. Телне өйрәнүгә кызыксынунычанлык арта, һәм татар телен милли мирасның бер өлеше буларак кабул итә.*
*Челтер –челтер чишмә ага*
*Һич тә тыймалы түгел.*
*Ә сулары шундый йомшак*
*Эчеп туймалы түгел.*
*Без барабыз чишмәбезнең*
*Салкын суын эчәргә.*
*Эчкәндә үзеннән-үзе*
*Баш иелә чишмәгә.* Дип бик белеп язган безнең шагыйребез- Роберт Миңнуллин.

«Чишмәләр иленә –туган телемдә!» проекты бик актуаль ЧӨНКИ:
- Чишмәләр янына балалар белән барып аның чисталыгын, матурлыгын, кирәклеген сөйләп –табигаткә, авылга - кече ватанга карта ярату, хөрмәт хисе тәрбияләнә.

-Чишмәләр турында матур шигырләр, җырлар. әкиятләр өйрәнү-сөйләм теле үстерүгә менә дигән метод. Чишмә буенда гаилә белән күмәк уеннар уйнап –гөреф гадәтләр күрсәтелә.

-Дусай авылы, рәисебез Рөстәм Нургалиевичның бабасы, Миннехан бабайның туган авылы. Кайчандыр ул да, Нургали абый да хазер без үзебезнең проектка алган чишмә суларын эчкән авылдашлар. Балаларга авыл тарихын өйрәткәндә –кызыклы мәглүмат. -Чишмәләрнең челтерәп аккан тавышы аша –халкыбызның моңлы җырларын ишетергә.

-Чишмә улагында курчак күлмәкләрен чайкап, кайчандыр әби-бабаларыбызның яшәү чыганагы булган чишмәгә рәхмәт әйтергә. Хәзерге тормышның җиңеллеген аңлатырга.

- Көянтә чиләкләр белән су алып кайтып, бераз гына җылытып балаларга эчертеп , тимер торбалар аша килгән колонка суыннан, йомшаклыгы белән аерылганын татып карау –лабораторик эш . Чишмә буеннан ташлар алып кайтып аларны төрле төсләргә буяп , шул ук елга буе балчыгы белән ташларны беркетеп, манара ясаулар бала күңе-лендә гомергә истә калачак.

Кечкенә генә челтерәп аккан чишмәбез - балага никадәр белем һәм тәрбия бирә! Үскәч чишмә буена килсә, балалар бакчасы белән тоташкан күпме хатирә яңара..!
Һәм инде без бу проект эшенә чын-чынлап, бөтен күңелебез белән бирелеп, әти-әниләрне безнең белән эшчәнлеккә тагы да якынайттык.
Чөнки һәр гаиләдә балаларга татар телендә сөйләм күнекмәләре бирелә дип әйтеп булмый.Заманча шартларда татарларның милли үзенчәлеге һәм гасырлар традицияләре югала. Хәзер авылларда да туган телен белүче татарлар да, күбрәк рус телендә сөйләшүне уңай күрә, бу бигрәктә күченеп авылларга кайтучы яшьләр арасында сизелә. Шулай итеп күтәрелгән проблеманы мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында гына түгел, аларнын әти-әниләренә дә кирәклеге барлыкка килде.

Безнең максат - бала тәрбияләүдә һәм туган телне үстерүдә әти-әниләргә һәрьяклап ярдәм күрсәтү. Балаларда һәм әти-әниләрдә татар халык авыз иҗатына, йолаларга, гореф-гадәтләргә таянып, алар белән күп кенә: “Борынгы татар өе”, “Милли ризыклар–табын түрендә”, ”Минем гаиләм булдыра!”- бәйгеләре, бәйрәмнәр,кызыклы продуктив чаралар аша аларда- кызыксыну уята алдык. Гаилә елында безнең проект бигрәк тә актуаль, көн кадагы темасы. Чөнки күп чаралар әти-әни, әби-бабайлар, баланың гаиләсе белән берлектә башкарыла.
Балалар бакчасы – умарта күчен хәтерләтүче урын ул. Нинди генә чаралар узмый монда! Ул – халыкның йола, календарь бәйрәмнәре дисеңме, әдәби атналар! Бакчабыз-да “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Карга боткасы”, “Сабан туе”, кебек бәйрәмнәрне үткәрү традициягә керде. Әлеге чаралар аша безнең балаларыбыз милли тәрбия ала, тарихы-бызны өйрәнә. Ә инде балалар белән төрле спектакльләрдән өзекләр өйрәнеп аларны сәхнәләштерүләр, әкиятләр кую- бала чактан ук сабый, туган телен ишетә, әкиятләр аша дөнья белән таныша. Алар балачакны эмоциональ яктан бизиләр. Әкиятләр балаларны мавыктыра, көлдерә, сөйләм телен үстерә балаларның сүзлек байлыгын арттыра, тел элементларын дөрес, төгәл, урынлы кулланырга мөмкинлек бирә. Балалар коллективта үзләрен ышанычлырак тотарга өйрәнә, аларның эчке дөньясы, сәләте ачыла. Балаларда туган теленә – татар теленә карата мәхәббәт уяна. Туган телендә дөрес сөйләшергә өйрәтү өчен, балаларны кызыксындыра алырлык сюжетлы уеннар оештыру баланың актив сөйләмен үстерә.
*Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган телебездә матур итеп сөйләшү,милли рухта тәрбияләү юнәлешендә балалар бакчасы мөмкинлекләре күптөрле. Аларны тормышка ашыру өчен, районыбыз территориясендә яшәүче халыкларның мәдәнияте һәм традицияләрен исәпкә алып, бакчабызда* татар, рус теленә өйрәтү, ныгыту һәм үстерү өчен белем бирү *предмет-тирәлек мохите булдырылды. Ягьни бездә:*
*-Милли костюмнарда (татар, рус,керәшен ), (әби,бабай) ландшафт курчаклары, кашовка белән ат;*
*-“Туган телем –иркә гөлем” Г.Тукайның “Әйт әле күбәләк” әкияте стендлары һәм этномәдәни регион өлеше буенча папкалар, татар орнаментлары белән ковер палас һәм сандыклар.*
*Үзебезнең авторлык дидактик эшләнмәләр, авторлык интерактив уеннар,*

- *«Колобок », “Шүрәле” әкиятенә макет - фанерадан фигуралар,*
-Балалар экспонатларны тотып, киеп карый алсыннар өчен *«Әби-бабамның кечкенә чагы» мини-музей,*
*-Мамадыш районы, балалар бакчасы һәм мәчет макетлары,*
*-“Чишмә башы” - фото зоналар бар. Бу проект балалар бакчасын милли макетларга баетты, уен киңлеге тагы да яхшырды, милли тирәлегебезне тагы да камилләштерде.*
*Татарча да яхшы бел,*
*Русча да яхшы бел,*
*Икесе дә безнең өчен,*
*Иң кирәкле, затлы тел.*
*Татарчасы – туган тел,*
*Безгә газиз булган тел,*
*Атаң - анаң, әби-бабаң*
*Сине сөя торган тел.*

Безнең якташыбыз Шәйхелислам ага Маннуров язган бу шигырь юлларында хаклык та бар. Ул хәзер дә актуаль. Балаларыбыз рус телендә дә иркен сөйләшәләр, яшьтәшләре белән аралашалар. Тел аралашу чарасы гына тугел, ә милләтне милләт иткән төп сыйфатларның берсе. Ул халыкның рухын, язмышын, акылын чагылдыра.
«Чишмәләр иленә –туган телемдә!» проектында, безнең алда, еш кына ата-аналарга, балага иң әүвәле аның туган теленең дә нәкъ башка телләр кебек үк кирәкле һәм затлы тел булуын аңлату бурычы тора. Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе булып халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф-гадәтләренә таяну . Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, моңлы бишек җырлары, әкиятләр - тел өйрәтүдә иң бай чыганак. Яшь буынны үз туган телендә сөйләшүче, халкын сөюче, иҗатка сәләтле буын итеп тәрбияләү, татар халкының электән килгән традицияләрен, гореф-гадәтләрен күрсәтеп , әдәпле шәхес тәрбияләүдә рухи мирасыбызны алдагы буыннарга тапшыруда –безгә районыбыз АК калфак оешмасы әбиләре, үзебезнең балаларыбызның әби- бабайлары , Шәйхи Маннур музей библиотекасы хезмәткәрләре зур өлеш кертә. Алар белән эшчәнлек –болар барысыда билингваль белем бирү кысаларында, татар теленә өйрәтүне җиңеләйтүгә, бердәмлеккә китерә. Татар халкының буыннан-буынга күчеп килгән иҗат җәүһәрләре балаларыбыз өчен зур тәрбия хәзинәсе.
Нәкъ менә балаларны халык мәдәнияте, традицияләре, гореф-гадәтләре чишмәсенә җәлеп итү балаларның туган телендә матур итеп сөйләшә белүенең, танып-белү Һәм әхлакый үсешенең бай чыганагы булып тора.
Татар халык авыз иҗаты аша бала туган телне өйрәнеп кенә калмый, гореф гадәтләр турында беренчел күзаллаулар барлыкка килә.
Чишмәләр алар авылның иң истәлекле урыны, гөмер –гомергә аның суы шифалы, чыккан урыны изге дип чутланган, чөнки алар җир астыннан калкып чыга. Туган телгә өйрәнүнең дә башы - балалар бакчасыннан башлана. Балага тәрбия һәм белем бирүне - *чишмә* итеп карасак, мәктәпкәчә белем бирү, балалар бакчасы! нәкь менә -*чишмәнең башы!*
Чишмәнең әһәмияте бик зур! *Авыл кешесе өчен элек тә, хәзер дә чишмәләр зур роль уйный.* Аның янында һәрвакыт куе яшеллек, җәнлекләргә су чыганагы, ә инде кешелек өчен әһәмиятен әйтеп бетергесез, ул аның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге. Чишмәләр - су чыганагы да, гүзәллек чыганагы да, җан тынычлыгы бирүче ял урыны да, экология дә, тәрбия-белем бирү чарасы да ул. Безнең очракта чишмәләр- *мавыктыргыч формада, тел тирәлегенә чумып балаларга татар телебезне өйрәтергә этәргеч бирүче дә..*